| Совет Нижнеураспугинского сельского поселения Зеленодольского муниципального района Республики Татарстан | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Т.Урысбага авыл жирлеге Советы |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**15 февраль 2019 ел** **№176**

Зеленодол муниципаль районы Т.Урысбага авыл жирлеге Советының 2017 елның 29 ноябреннән 119нчы номерлы «Зеленодол муниципаль районы Т.Урысбага авыл жирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында Кагыйдәне раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»гы (№25-ФЗ 02.03.2007 ел) Федераль законга, Татарстан РЕспубликасында муниципаль хезмәт Кодексына, Татарстан Республикасы «Зеленодол муниципаль районы Т.Урысбага авыл жирлеге муниципаль берәмлеге Уставына яраклы рәвештә, Зеленодол муниципаль район Т.Урысбага авыл жирлеге Советы түбәндәге карар итте:

1.«Зеленодол муниципаль районы Т.Урысбага авыл жирлеге муниципаль хезмәт Кагыйдәсен раслау турында»гы Зеленодол муниципаль район Т.Урысбага авыл жирлеге Советының 2017 ел 29 ноябрендә чыккан 119нчы номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) 2нче маддәнең 2.3 бүлеген «Зеленодол муниципаль районның сайлау комиссиясе рәисе» сүзләреннән соң, «яки яллаучы (эш бирүче) вәкиленең бурычларын үтәргә вәкаләтле башка зат» сүзләре белән тулыландырырга;

1.2) 7нче маддәнең 7.2 бүлегенең 2нче бүлемтеген яңа редакциядә бәян итәргә:

«2) муниципаль хезмәт стажына яки белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына:

муниципаль хезмәтнең иң югары вазифалары буенча - муниципаль хезмәт стажы ике елдан да ким булмаган яки белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча дүрт елдан да ким булмаган эш стажы;

муниципаль хезмәтнең төп вазыйфалары буенча – муниципаль хезмәт стажы бер елдан ким булмаган яки белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча ике елдан ким булмаган эш стажы.»;

1.3) 7нче маддәнең 7.3 бүлемтегендә «муниципаль хезмәт вазифалары» сүзләреннән соң «җитәкче,» сүзе белән тулыландырырга;

1.4) 7.4 бүлемтеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.4. Белгеч яки магистр кызыл дипломлы затлар өчен диплом биргән көннән алып өч ел дәвамында муниципаль хезмәт стажына яки муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы вазифаларын алмаштыру өчен белгечлек буенча эш стажына квалификацион таләпләр билгеләнә - муниципаль хезмәт стажы ярты ел яки белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажы бер ел булырга тиеш.»;

1.5) 7нче маддәнең 7.6 бүлеген 7.9нчы бүлеге дип исәпләргә;

1.6) 7нче маддәне 7.6, 7.7, 7.8 бүлекләре белән түбәндәге эчтәлектә тулыландырырга:

«7.6. Муниципаль хезмәт стажын билгеләгән вакытта тиешле вазифаи төркемнәргә караган дәүләт гражданлык хезмәтендәге яки хәрби һәм федераль

дәүләт хезмәтләренә  тиңдәш вазыйфалар башкару буенча эш стажы исәпкә алына.

7.7. Әгәр муниципаль хезмәткәрнең вазифаи күрсәтмәсе тарафыннан муниципаль хезмәт вазифасын үтәү өчен кирәк булган белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә квалификация таләпләре каралган булса, әлеге белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажын исәпләгәндә, гражданин (муниципаль хезмәткәрләр) белем турында документ һәм (яки) күрсәтелгән белгечлек, әзерлек юнәлеше турында квалификация алганнан соң, бу белгечлек буенча эш периоды стажга кертелә.

7.8. Әгәр муниципаль хезмәткәрнең вазифаи инструкциясе тарафыннан белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча квалификация таләпләре каралмаган булса, белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажын исәпләгәндә күрсәтелгән стажга гражданинның (муниципаль хезмәткәрнең) муниципаль хезмәт вазифасын башкарганда кирәкле белем һәм осталык алынган, әлеге дәрәҗәдәге муниципаль хезмәт вазыйфаларын үтәү өчен квалификация таләпләренә туры килә торган һөнәри белем турында документ алганнан соң булган, эш периоды кертелә.»;

1.7) 11нче маддәне 11.2.1 бүлемтеге белән түбәндәге эчтәлектә тулыландырырга:

«11.2.1. Гражданин, Зеленодол муниципаль районының вәкиллекле органы рәисе, Зеленодол муниципаль район башлыгы, Башкарма комитеты җитәкчесе, Зеленодол муниципаль районы территориясендә урнашкан суд һәм хокук саклау органнары җитәкчеләре белән якын туганнар (əти-әнисе, ире-хатыны, балалары, абый-эне, апа-сеңел, шулай ук, иренең яки хатынының шундый туганнары) булган очракта, ул рәис, рәис урынбасары һәм Зеленодол муниципаль районының контроль-хисап аудиторы вазифасына билгеләнә, ә муниципаль хезмәткәр рәис, рәис урынбасары һәм Зеленодол муниципаль районы контроль-хисап органы аудиторы вазифаларын башкара алмый.»;

1.8) 11нче маддә 11.4 бүлегенең 2нче бүлемтәсен яңа редакциядә бәян итәргә:

«2)  шәхси яки ышанычлы затлар аша эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнергә, коммерция оешмасы белән идарә итүдә яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга (сәяси партия белән идарә итүдә катнашудан тыш; түләүсез нигездә профсоюз органы белән идарә итүдә катнашудан тыш; шул исәптән сайлау комиссиясе аппаратында җирле үзидарә органында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы; съездда (конференциядә) яки башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек, милекчеләр ширкәтләренең гомуми җыелышында катнашу; коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу; (сәяси партиядән һәм профсоюз органыннан, шул исәптән җирле үзидарә органында, җирле үзидарә сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органыннан тыш) бердәнбер башкарма орган сыйфатында яки аларның коллегиаль идарә органнары составына эшкә алучы вәкиле рөхсәте белән керү, ул муниципаль хокукый акт белән билгеләнгән тәртиптә алынган), җирле үзидарә органнарында һәм ревизия комиссиясендә җирле үзидарә мәнфәгатьләрен бушлай тәкъдим итүдән тыш, гамәлгә куючы (акционер) , муниципаль милектәге акцияләр (устав капиталында катнашу өлешләре) оештыру яки идарә итү вәкаләтләрен җирле үзидарә исеменнән гамәлгә ашыру тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә; федераль законнарда каралган башка очракларда;»;

1.9) 23нче маддәнең 23.14 бүлегендә беренче абзацта «фәннәр докторы» сүзләреннән соң ,«Татарстан Республикасының мактаулы исеме» сүзләре белән тулыландырырга;

1.10) 29нчы маддәнең 29.3 бүлеген 2.1 бүлемтәсе белән түбәндәге эчтәлектә тулыландырырга:

«2.1) фактагы коррупцион хокук бозу шартлары бәян ителгән коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча тиешле муниципаль органның

кадрлар хезмәте бүлекчәсе доклады һәм муниципаль хезмәткәрнең бары тик аның ризалыгыннан гына һәм коррупциячел хокук бозу фактын тану шарты белән генә (ышанычны югалтуга бәйле рәвештә эштән азат итү рәвешендә түләтүдән тыш) язмача аңлатмалары;».

2. Әлеге карарны дәүләт теркәлүе узганнан соң «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокук мәгълүматы рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр порталы составындагы Зеленодол муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Түбән Ураспуги авылы, Центральная урамы, 62а йорт (җирлек хакимияте бинасы), Түбән Ураспуги авылы, Үзәк урамы, 63а йорт (мәдәният йорты бинасы) адреслары буенча урнашкан Түбән Урысбага авыл җирлеге мәгълүмат стендларына урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Зеленодольск муниципаль районы Т.Урысбага авыл жирлеге башлыгына йөкләргә.

**Т.Урысбага авыл жирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе** **Х.Х.Сибгатуллин**